| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**К А Р А Р**

Иске Чүпрәле авылы

12 февраль 2019 ел № 53/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" гы 02.03.2007 ел № 25-ФЗ Федераль законга, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 32 матдәсенә туры китереп, Чүпрәле районы прокурорының 16.01.2019 ел протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 16.09.2008 ел № 32/3 Карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәнең (14.04.2009 ел № 39/1, 05.04.2010 ел № 48/3, 26.06.2013 ел № 33/1, 04.04.2014 ел № 43/3, 04.08.2015 ел № 66/2, 18.04.2016 ел № 10/1, 04.08.2017 ел № 26/1, 17.10.2017 ел № 30/1 редакцияләрендә) 3 бүлегенең 3.2 өлешенә, түбәндәге эчтәлектәге 3.2.7-3.2.8 пунктларын өстәп, үзгәрешләр кертәргә:

«3.2.7. Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы Рәисе, Иске Чүпрәле авыл җирлеге Башлыгы, Башкарма комитет Җитәкчесе, Район территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыгы яки туганлык үзлекләре (ата-анасы, ире яки хатыны, баласы, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук ире яки хатынының ир туганнары, кыз туганнары, ата-анасы, баласы һәм балаларының ире яки хатыны) булган очракларда граждан контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазифаларына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазифаларын били алмый.

3.2.8. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, Иске Чүпрәле авыл җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын

булдырмау максатында, күрсәтелгән вазифаны биләгән чорда Районның шушы җирле үзидарә органының, сайлау комиссиясе аппаратының сайланып куелган профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.».

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Башлыгы: Р.Д.Низамов